ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.05.2019 ел Баулы шәһәре №155

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2019
елның 19 апрелендә каул ителгән
109нчы карары белән расланган
Торак бинаны үзгәртеп коруга һәм
(яки) планын үзгәртүгә рөхсәт бирү
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

2018 елның 27 декабрендә кабул ителгән 558-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп тезүне һәм (яки) планын үзгәртүне җайга салучы нормаларны тәртипкә салу өлешендә Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 апрелендә каул ителгән 109нчы карары белән расланган Торак бинаны үзгәртеп коруга һәм (яки) планын үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Регламент исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Торак йорттагы бинаны үзгәртеп коруга һәм (яки) планын үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты»;

1нче «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

- 1.1. пунктта “торак  биналар” сүзләрен “торак йорттагы бүлмәләр” сүзләренә алмаштырырга;

- 1.5 пунктның 4нче һәм 5нче абзацларында “торак биналар” сүзләрен “торак йорттагы бүлмәләр” сүзләренә алмаштырырга;

2нче «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

- 2.1 һәм 2.3. пунктчаларда “торак биналар” сүзләрен “торак йорттагы бүлмәләр” сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктының 5нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) күпфатирлы йортта үзгәртеп корыла һәм (яки) планы үзгәртелә торган бинаны үзгәртеп коры һәм (яки) планын үзгәртү проекты (тиешле тәртиптә

әзерләнгән һәм рәсмиләштерелгән), әгәр күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп кору һәм (яисә) планын үзгәртү күпфатирлы йортта гомуми милекнең бер өлешен әлеге бинага кушудан башка мөмкин булммаса, шулай ук күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең күпфатирлы йорттагы барлык милекчеләренең мондый үзгәртеп коруга һәм (яисә) планны үзгәртүгәа ризалыгы турында уртак җыелышы беркетмәсе, (Россия Федерациясе Торак кодексының 40 статьясындагы 2 өлешендә каралган);

социаль наем шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йортта тезекләндерелә торган һәм (яисә) планы үзгәртелә торган бинаны биләгән наемга алучының гаиләсенең барлык әгъзаларыннан язмача ризалык (мөрәҗәгать итүче күпфатирлы йорттагы үзгәртеп корылучы һәм (яисә) планы үзгәртелүче бинаны социаль наем шартнамәсе буенча арендага бирүченең әлеге пунктта каралган документларны тапшырырга вәкаләтле наемга алучысы булса);

- 2.5 пунктының 11нче абзацында “торак бина” сүзләрен “торак йорттагы бүлмәләр” сүзләренә алмаштырырга;

3нче “Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрнең ерак урнашкан эш урыннарында башкару үзенчәлекләре» бүлегендә:

- 3.5.1 пунктында. “торак бинаның” сүзләрен “торак йорттагы бүлмәләр” сүзләренә алмаштырырга;

регламентка 1нче "Торак бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) планын үзгәртү турында гариза» кушымтасында “торак бина” сүзләрен “торак йорттагы бүлмәләр” сүзләренә алмаштырырга;

регламентка 2нче «Торак бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) планын үзгәртүне килештерү турында карар кабул итүне раслый торган документ формасы» кушымтасында “торак бина” сүзләрен “торак йорттагы бүлмәләр” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны http://www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://www.bavly.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров